УДК 94(44)

***Галимҗан Ибраһимов***

# ПАРИЖ ПРОЛЕТАРИАТЫНЫҢ ДИКТАТУРАСЫ

Вниманию читателей предлагается статья Галимджана Ибрагимова «Париж пролетариатының диктатурасы», опубликованная 18 марта 1920 года в газете «Кызыл Армия». В статье дается краткий экскурс истории Коммуны, характеристика событию. На кириллице статья печатается впервые.
**Ключевые слова**: Галимджан Ибрагимов, история, Парижская коммуна, татарская периодическая печать.

The article by Galimjan Ibragimov «Dictatorship of the Parisian proletarians», published on March 18, 1920 in the newspaper «Kyzyl Army», is offered to the attention of readers. The article gives a brief overview of the history of the Commune, a description of the event. The article is published in Cyrillic for the first time.
**Keywords:** Galimjan Ibragimov, history, Paris commune, Tatar periodical press.

## 1871 ел – март 18 – май 28

### 1

1870 ел.

Үз тупрагына сыеныша алмаган ике капиталист хөкүмәт Бисмарк[1] белән Өченче Наполеон[2] арасында сугыш башлана; – Франция җиңелә. – «Седан»дагы һәлакәт империянең актык көне; [18]48 елдагы революцияне кан эчендә буып, тәхеткә менгән император «Вильһельмсхёэ»[3] дигән йирдә немец штабына әсир төшә; бунының нәтиҗәсендә Парижда пролетариат кузгала; – дүртенче сентябрьдә Өченче җөмһүрият игълан кылына; хөкүмәт буржуалар, аларның илчесе булган Жюль Фавр[4] һәм Тьер[5] шайкасы кулына эләгә; – капиталның бу хаин, сатлык агентлары тарафыннан төзелгән «Вакытлы хөкүмәт», көчәеп барган революцияне басу өчен, баштанаяк коралланган Париж халкына каршы «Ватан дошманы», ләкин сыйнфый мәнфәгать дусты Бисмарк белән берләшергә астыртын планнар йөртә; революционер халыкның алгы сафында барган пролетариат революционер Парижны Пруссия юнкерлары итекләре астына ташларга хәзерләнгән «Вакытлы хөкүмәт» шайкасын себереп түгә дә үз көче белән яшәүче бөтен Парижның гадәттән тыш ялкынлы алкышлары астында:

«Париж коммунасы!!» игълан кыла. Буржуазия үзенең вакытлы хөкүмәте, поп, архәрәйләре, барлык кара гөруһлары белән Версальгә кача.

Бу – 1871 ел, март 18 дә иде.

2

Шул көннән алып бөтен хакимият эшче халык кулына күчә. Иске хөкүмәт аппараты җимерелеп, аның урынына төзелгән Коммуна идарәсе бөтенләй эшчеләрдән яки аларның сыйнфый мәнфәгатен яклаучылардан – социалистлардан – гына сайлана һәм бу яңа дәүләт аппаратының бөтен эшләре капитализмны җимерү, үз көче белән яшәүче халыкның икътисади азатлыгы нигезенә юнәлә. Дин исеменнән, Алла исеменнән алтын каруннарына ялчылык иткән чиркәү, монастырьларның байлыгы халыкка алына, дин хөкүмәттән аерылган итеп игълан кылына, мәктәптән дин дәресләре, поплар, тәреләр сөрелә, дини мөәссәсәләр (*оешмалар*) өчен хәзинәдән бирелә торган ярдәмнәр туктала. Түләү, квартир мәсьәләләре ярлы халык файдасына муафыйк ясалып, декретлар чыга. Версальгә җыелган контрреволюционер Вакытлы хөкүмәтнең туктаусыз һөҗүменә, сугышуына, Бисмаркның Париж коммунасы [туып] ятуына карамастан, шул [...]* каршы корал белән революцияне яклау белән бергә, Коммуна мәмләкәтенең икътисади тормышын иҗтимагый азатлык нигезендә төзи башлау чараларына тотына – аңарчы бер уч капиталистлар кулында булган завод-фабрик, зур һөнәрханәләрне бөтен халык милке – хәзергечә, национализация ясау планнары хакында декрет чыгара.

Коммунаның эчке төзелеше дә шул рухта бара. Элеккеге гаскәр бетерелә, аның урынына революционер халык үзе коралланып, батальоннар төзелә. Мәэмүрләр (*чиновниклар*) һәммәсе теләгән вакытта халык тарафыннан сайлана һәм төшерелә. Аларның жалунияләре уртача эшченең хезмәт хакы белән тигезләнә – иң зуры (2400) сумнар чамасы.

3

Ләкин хәлләр бик артык авыр иде. Тышкы сугыш, Бисмаркның мөхасарәсе (*камап алуы*), версальчеләрнең һөҗүме, шулай итеп Парижның бөтен дөньядан өзелүе (хәзергечә блокада), болар нәтиҗәсендә туган бик артык каты ихтыяҗ бу бөек әмәлләрнең тиешенчә гамәлгә керүенә юл бирмәделәр.

Версальдәге контрлар бер яктан Коммуна белән, гүя, килешү хакында рәһенгә (*заложникка*) алынганнарны алмашу хакында сөйләшеп, күз буяп маташсалар, икенче яктан, Бисмарктан: сугыш вакытында әсир төшкән француз солдатларын кайтаруны ялынып сорыйлар иде. Пруссия юнкерлары өчен Париж пролетариаты артык зур дошман булганга, Бисмарк Версальнең бу ялынуларына колак салды – әсирләрне кайтара башлады, болардан Вакытлы хөкүмәт үзенең көчләрен арттырды.

Озак, каты, канлы сугышлардан соң, революция җиңелде.

Май 28 дә Коммуна һәлак булды. Ләкин Париж пролетариаты актык тамчы канынача сугышты. Зурлар, ирләр генә түгел, хатыннар,

* Чыганак таушалган булу сәбәпле, сүзләр укылмый.

картлар, балалар да пайтәхетнең (*башкаланың)* урамнарында баррикадалар ясап, котырган эт төсенә кергән буржуага каршы:

– «Яшәсен Коммуна!!» авазлары белән каһарманнарча көрәшеп җан бирделәр.

4

Үз сыйныфының вәхшәтен яшерергә маташкан, буржуазиягә ялчылык иткән галимнәр, әдипләр изге социализм идеалы юлында һәлак булган Париж пролетариатының санын 30–35 мең тирәсендә дип күрсәтәләр. Ләкин вакыйганың эчендә булучылар бу канлы фаҗигада эшче халыкның корбаннары [...]* сөргеннәрдә, зинданнарда, дар агачларында һәлак булганнарның барлыгын бергә җыйганда 150 меңнән артык булганлыгын исбат итәләр.

5

Бу корбаннар, бу каннар әрәм булдымы? Пролетариат болардан үзенең җиңүе өчен ни нәрсә алды?

Бу сөаль куелырга, аңа җавап соралып торырга тиешле түгел.

Бөтен тарих буенча шулай килә, гыйльми, әдәби революцияләр, сәяси, иҗтимагый азатлыклар, адәм балаларының бәхете, сәгадәте, идеалы юлындагы алга атлаулар һәммәсе-һәммәсе авыр корбаннар, канлы фаҗигалар аша гына була.

Париж коммуналарының [18]71 елда түккән каннары да – инсаниятнең бөек азатлык идеалларына баруда биргән шәһитләре, корбаннарыдыр. Буржуа һәм аңа сатылган әдипләр, шагыйрьләр ул җитмеш көнне ничаклы каралтырга тырышмасыннар, бөтендөнья пролетариаты шул канлы фаҗигадан үзенә зур көч ала, үзенең авыр көрәшендә Париж коммуналарын бөек юлбашчылар дип таный, яшь буын шулар хатирәсе мәктәбендә тәрбияләнә, шулар эзеннән барырга ант эчеп үсә.

Дини хыялларга бирелгән караңгы гаммәдә пәйгамбәрләр, әүлияләр каберен зиярәт итү гадәте бармы, боларга елның мәгълүм вакытында барып ярдәм сорыйлармы? – Париж пролетариаты да [18]71 ел Коммуналарның каберстанын шундый бер изге урын дип тәкъдис итә (*ышана)*, һәр ел май 28дә шул бөек әмәл юлында корбан булган шәһитләр, әүлияләр зиратына барып, аларга үзенең сәламен ирештерә, Коммуналарның кабер туфрагы өстендә Коммуналар үзләрен корбан иткән социализм идеалы дөньяга туганчы көрәшергә, дөньяда иҗтимагый азатлык кояшы туганчы кулдан корал ташламаска ант эчәләр.

Бер Париж түгел, бөтен Франция, бөтендөнья пролетариаты бу антка кушыла, шул авыр фаҗигадан үзенә бетмәс-төкәнмәс куәт, гайрәт һәм иман ала.

6

Бүген совет димезме, иҗтимагый революция димезме? – Без Париж коммуналарының идеалын үз йөрәгемездә янганын күрсәтәмез.

* Чыганак таушалган булу сәбәпле, сүзләр укылмый.

[18]71 ел фаҗигасы гыйльми социализмның дәүләт һәм капитализмнан социализмга күчү дәверендәге идарә мәсьәләсендә ачык, катгый юл салды, буны тәхлил (*анализлау*) нәтиҗәсендә Маркс, Энгельс безгә: күчү дәвере – тик пролетариат диктатурасы рәвешендә булачагын, пролетариат иске аппаратны алып, бөтен көенчә юлга куймаячагын, бәлки аны үзенең сыйнфый мәнфәгатенә каратып ясаячагын гыйльми рәвештә исбат иттеләр. Русия революциясе шул Париж коммунасын советлар идарәсе ысулына салып гамәлгә куйды. Хәзер бөтендөнья пролетариаты үзенә бердәнбер юл итеп шуны иман итте.

Русиянең эшче, крәстияне, Гаребнең пролетариаты, Төркиянең гамәләсе (*эшчеләре*), хәммале (*йөк ташучысы*), Мисырның фәлляхы (*игенчесе, крестьяны*), Төркестанның диһканы (*игенчесе*), кәмбәгальләре (*ярлылары*) шул бөек идеал наменә берләшеп, моннан 50 ел элек Париж коммуналары: «Безнең байрак – бөтендөнья җөмһүрияте байрагы!» – дигән шигарьләрен гамәлгә куялар.

Мәкаләмне инглиз сүзе белән бетерәм:

Диктатураның нәрсә икәнен беләсеңез килсә, Париж коммунасына караңыз – ул пролетариат диктатурасы иде!

### Искәрмәләр

[1] *Бисмарк* – Германия империясенең беренче канцлеры Отто Эдуард Леопольд фон Бисмарк-Шёнхаузен (1815–1898).

[2] *Наполеон III* – Икенче Франция республикасының беренче президенты, Икенче империя императоры Шарль Луи Наполен Бонапарт (1808–1873).

[3] *Вильһельмсхёэ* – Германиядә Кассель шәһәрендә урнашкан ландграф Гессен-Кассельскийлар сарае.

[4] *Жюль Фавр* – Франция сәяси эшлеклесе Жюль Фавр (1809–1880).

[5] *Тьер* – Франция сәяси эшлеклесе, тарихчы Мари Жозеф Луи Адольф Тьер (1797–1877).

*Текст һәм искәрмәләрне басмага филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы** әзерләде*